РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.03.2024 № 205-п

«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 ноябрендәге 1187-п номерлы карары белән расланган «2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның паспорты таблицасында «6 Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | Программаны 2022-2025 елларга финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 45,000 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2022 ел - 15,000 мең сум;<br>2023 ел - 15,000 мең сум;<br>2024 ел - 15,000 мең сум;<br>2025 ел - 0,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәллəштереләчәк. |

»;

1.2. 3 бүлек. «Программаны ресурс белән тәэмин итүне» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Программаны ресурслар белән тәэмин итү**

Программаны 2022-2025 елларга финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 45,000 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2022 ел - 15,000 мең сум;
2023 ел - 15,000 мең сум;
2024 ел - 15,000 мең сум;
2025 ел - 0,000 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

1.3. Программаның 2 нче кушымтасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының инвестицион үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - инвестицион үсеш һәм эшкуарлыкка ярдәм бүлеге башлыгы И.И. Котдусовка йөкләргә.

Саба муниципаль районының
Башкарма комитет
Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 05 мартындагы 205-п номерлы карарына 1 номерлы кушымта

«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» муниципаль программасына 2 номерлы кушымта

**«2022-2025 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА СОЦИАЛЬ ЮНӘЛЕШЛЕ КОММЕРЦИЯГӘ КАРАМАГАН ОЕШМАЛАРГА ЯРДӘМ " МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ТӨП ЧАРАЛАРЫН ФИНАНСЛАУ**

| Төп чаралар исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Финанс чыганагын күрсәтеп финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| | | | Саба муниципаль районы бюджеты акчалары | | | |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының социаль проектлар буенча коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмалар чараларын уздыру чыгымнары өлешен финанслау | ИК, ФБП, СОНКО | 2022 - 2025 ел | 15,000 | 15,000 | 15,000 | 0,000 |
| **Барлыгы** | | | **15,000** | **15,000** | **0,000** | **0,000** |
| **БАРЛЫГЫ** | | | **45,000** | | | |